| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| 422054, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36<br>тел. (84362) 41-2-11 | 422054, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт<br>тел. (84362) 41-2-11 |

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ  КАРАР
23.09.2019  №13

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2009 нчы елның 11 нче декабрендә кабул ителгән 20 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 2019 нчы елның 10 нчы сентябрендә бирелгән 02-01-20-2019 нчы номерлы хаты нигезендә Олы Шыңар авыл җирлеге Уставына туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 11.12.2009 елгы №20 карары белән расланган Олы Шыңар авыл җирлеге Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1 Регламентның 6 нчы булеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:
"Статья 34.1
1. Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Олы Шыңар авыл җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.
2. Советның ачык утырышларында Олы Шыңар авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.
3. Совет тарафыннан аларның эшчәнлегенә караган сорауларны караганда, башкарма комитет эшчеләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.
4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.
Катнашу турында таләп, утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның көне, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.
5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел. (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен суз бирелергә мөмкин."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/shinar адресы буенча һәм җирлекнең мәгълумати стендларында бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов